# 3 САНЛЫ ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

30 ноябрь 2021 ел

Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Чыпчык авыл җирлеге Чыпчык торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында

“Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында”, 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, “Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында”, 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы законының 35 статьясы нигезендә, 2021 елның 28 ноябрендә 17 сәгать 00 минутта, 2021 елның 29 ноябрендә 18 сәгать 00 минутта, 2021 елның 30 ноябрендә 18 сәгать 00 минутта уздырылган “Сез 2022 елда Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Чыпчык авыл җирлеге Чыпчык авылы территориясендә даими яшәүче һәм яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 500 (Биш йөз) сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм җыелган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияткә ия мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерү белән килешәсезме?” дигән мәсьәлә буенча этаплап гражданнар җыены нәтиҗәләре буенча беркетмә төзелде

1) Поселок эчендәге юлларга вак таш салу;
2) Су алу өчен янгын пирсы урнаштыру;
3) Балалар мәйданчыгын коймалар.
4) Чыпчык авылы артезиан скважинасына су басымын үзгәртеп кору һәм урнаштыру.
5) Бөек Ватан сугышында катнашучыларга куелган һәйкәлне ремонтлау

Аерым мәсьәләләр буенча экономия булган очракта Чыпчык авыл җирлеге Башкарма комитетына акчаларны, җыен белән билгеләнгән башка мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерергә рөхсәт итәргә.

«РИЗА» «КАРШЫ».

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турында беркетмә нигезендә:

Сайлау хокукына ия җыенда катнашучылар исемлегенә гражданнар җыенында катнашучы 1248 (Бер мең ике йөз кырык сигез) кеше кертелгән, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар саны 648 (Алты йөз кырык сигез) кеше, бу 52%ны тәшкил итә.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучылар түбәндәгечә бүленде: “Риза” позициясе өчен гражданнар җыенында 648 (Алты йөз кырык сигез) катнашучы тавыш бирде; “Каршы” позициясе өчен җыенда катнашучы 0 (Ноль) кеше тавыш бирде.

Бәян ителгәннәрдән чыгып, гражданнар җыены түбәндәгечә хәл итте:

1.Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Чыпчык авыл җирлеге Чыпчык торак пунктында гражданнар җыенын узган дип, гражданнар җыены нәтиҗәләрен дөрес дип танырга.

2.“Сез 2020 елда Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Чыпчык авыл җирлеге Чыпчык авылы территориясендә даими яшәүче һәм яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 500 (Биш йөз) сум күләмендә үзара салым

кертүгә һәм җыелган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияткә ия мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерү белән килешәсезме?”

1) Поселок эчендәге юлларга вак таш салу;

2) Су алу өчен янгын пирсы урнаштыру;

3) Балалар мәйданчыгын коймалар.

4) Чыпчык авылы артезиан скважинасына су басымын үзгәртеп кору һәм урнаштыру.

5) Бөек Ватан сугышында катнашучыларга куелган һәйкәлне ремонтлау дигән мәсьәлә буенча кабул ителгән дип санарга.

Аерым мәсьәләләр буенча экономия булган очракта Чыпчык авыл җирлеге Башкарма комитетына акчаларны, җыен белән билгеләнгән башка мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерергә рөхсәт итәргә.

3. Әлеге карарны Биектау муниципаль районы рәсми сайтында Интернет челтәрендә http://vysokaya-gora.tatarstan.ru веб-адресы һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында “Интернет” мәгълүмат-телекоммуникацияләр челтәрендә http://pravo.tatarstan.ru бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлар регистрына кертү өчен җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Чыпчык авыл җирлеге башлыгы И.Р.Җиһаншин

Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы
Чыпчык авыл җирлеге Советы
Совет Чепчуговского сельского поселения
ИНН 1616004928
Республика Татарстан Высокогорский муниципальный район